КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 июнь г.Казань № 727

2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында

2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын (алга таба – Тәртип);

2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив

чыгымнар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын Тәртип нигезендә гамәлгә ашыруны оештырырга;

«Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» проектын гамәлгә ашыруны методик яктан тәэмин итәргә.

5. 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» проектын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максат өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 июнь, 727 нче
карары белән расланды

## 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә һәм шартлар 2023 – 2026 елларда Татарстан Республикасында «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру механизмын (алга таба – Тәртип) билгели.

1.2. 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру максатларында, аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру дигәндә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган эшләмәгән инвалидларны эшкә урнаштыру белән тәэмин итү максатларында «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәткәндә коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан башкарыла торган, Тәртипнең кушымтасында күрсәтелгән чаралар комплексы аңлашыла.

Тәртиптә кулланыла торган башка төп төшенчәләр «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карары белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясендә кулланылган мәгънәләрдә кулланыла.

1.3. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» дигән хезмәт күрсәтү социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче коммерциягә карамаган оешмалар (алга таба – коммерциягә карамаган оешма) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## II. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтеннән файдаланучылар һәм аны күрсәтү шартлары

2.1. Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган, эшкә сәләтле яшькә җиткән, Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән, Тәртипнең 2.2 пунктындагы зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмаган, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган һәм федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында һөнәри реабилитацияләү яки абилитация чаралары тәкъдим ителгән һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган инвалидларга карата гамәлгә ашырыла.

2.2. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә карата зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре – авыр психик бозылулар, эпилепсиянең авыр формасы, карантин йогышлы авырулар, хроник алкоголизм, венерик, хроник тире авырулары, туберкулезның актив формалары, очлыклар гангренасы, кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авырулар.

2.3. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте бушлай күрсәтелә.

## III. Гражданны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул итү тәртибе

3.1. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы карар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының граждан яшәү (тору) урыны буенча социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – территориаль социаль яклау органы) тарафыннан аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган форма буенча «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать иткәндә кабул ителә.

Гариза биргәндә аңа түбәндәге документлар теркәлә:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның Тәртипнең 2.2 пунктында каралган «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе (алга таба – медицина оешмасы бәяләмәсе);

табиб-психиатр тарафыннан бирелгән медицина бәяләмәсе.

Территориаль социаль яклау органы аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид тарафыннан гариза бирелгән көннән өч көн эчендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул итә.

3.2. Территориаль социаль яклау органы ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтелүгә гариза биргәндә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары

булган инвалидның хезмәт мөнәсәбәтләре булмавы турында белешмә ала.

3.3. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көне эчендә территориаль социаль яклау органы аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка төзелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасына «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турында язып куя:

агымдагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча башкару срогы белән 10 бүлекнең V бүлекчәсендә;

12 бүлектә коммерциягә карамаган оешманың исемен, урнашу урыннары адресын, элемтәгә керү мәгълүматын (телефоннарын, электрон почта адресларын) күрсәтә.

3.4. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турындагы карарны территориаль социаль яклау органы кабул итә. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, территориаль социаль яклау органы мондый карар кабул ителгән көннән соң килә торган бер эш көне эчендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка кабул ителгән карар турында язма хәбәрнамә җибәрә.

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

хезмәт законнары нигезендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булу;

инвалидның реабилитацияләү яки абилитацияләү буенча индивидуаль программасында эшкә урнашуда ярдәм күрсәтүгә мохтаҗлык турында билге булмау;

табиб-психиатр тарафыннан бирелгән медицина бәяләмәсенең гамәлдә булу вакыты чыгу.

3.5. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар кабул ителгән көннән соң килә торган бер эш көне эчендә территориаль социаль яклау органы аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка кабул ителгән карар турында язма хәбәрнамә җибәрә.

3.6. Территориаль социаль яклау органы түбәндәгеләрне формалаштыра:

реабилитацияләү яки абилитацияләү индивидуаль программасына «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтелгән аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларның исемлеген;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларның шәхси делолары, аларга түбәндәгеләр теркәлә:

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турында гариза;

Тәртипнең 2.2 пунктында каралган «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмау турында бәяләмә;

социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы күчермәсе;

инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр.

## IV. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турында шартнамә төзү һәм аны өзү тәртибе

4.1. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте Министрлык раслаган форма буенча «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче коммерциягә карамаган оешма белән граждан арасында төзелә торган «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турындагы шартнамә (алга таба – хезмәт күрсәтү турында шартнамә) нигезендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка күрсәтелә.

Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид коммерциягә карамаган оешмага Министрлык расланган форма буенча гариза бирә, аңа түбәндәге документларның күчермәләрен терки:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның шәхесен раслый торган документ;

шәхесне раслый торган документ һәм аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид тарафыннан вәкаләтле затның вәкаләтләрен раслый торган документ (гариза һәм документлар аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид тарафыннан вәкаләтле зат тапшырган очракта күрсәтелә);

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтелгән социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы;

инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы;

Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмау турында бәяләмә.

Документларның күчермәләре коммерциягә карамаган оешмага бирелә.

Әгәр документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) тарафыннан таныкланмаган булса, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм коммерциягә карамаган оешма белгече тарафыннан таныклана.

4.2. Коммерциягә карамаган оешма һәм аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид арасында хезмәт күрсәтү турында шартнамә, Тәртипнең 5.1 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен теркәп, гариза тапшырылган көннән соң килә торган өч эш көне эчендә төзелә.

Хезмәт күрсәтү турында шартнамә агымдагы календарь елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлдә булу срогы белән төзелә.

4.3. Хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәдә түбәндәгеләр карала:

а) үз эченә түбәндәгеләрне ала торган «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүче коммерциягә карамаган оешма тарафыннан башкарыла торган чаралар исемлеге:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларны эш белән тәэмин итүне оештырганда ярдәм күрсәтеп торуның индивидуаль планнарын эшләү;

«Россиядә эш» порталында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны теркәү;

һөнәри диагностика үткәрү (тест үткәрүне оештыру, эшчәнлекнең мөмкин булган төрләрен сайлау, предприятиеләргә һәм оешмаларга кимендә ике экскурсия үткәрү);

инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасындагы тәкъдимнамәләр нигезендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидлар өчен яраклы эш вариантларын эзләү максатларында Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның резюмесын әзерләү һәм эш бирүчеләр белән әңгәмә уздырганда ярдәм күрсәтү;

эш бирүчене эзләү, эш бирүче вәкилләре белән очрашу (аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның хезмәт шартлары үзенчәлекләрен һәм эш көне тәртибен билгеләү);

медицина комиссиясен узу өчен документлар җыюда ярдәм күрсәтү, эш урынына кадәр озатып бару;

хезмәт шартнамәсе төзегәндә ярдәм күрсәтеп тору;

ике ай дәвамында (кимендә 14 эш көне) эш урынында ярдәм күрсәтеп торуны гамәлгә ашыру;

хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәнең яклары белән хисап аенда күрсәтелгән хезмәтне тапшыру-кабул итү актына имза кую;

б) «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү сроклары, шул исәптән әлеге пунктның «а» пунктчасында каралган чараларны башкару сроклары;

в) хезмәт күрсәтү турында шартнамә якларының хокуклары һәм бурычлары;

г) хезмәт күрсәтү турында шартнамәне туктатып тору һәм өзү нигезләре, шул исәптән Тәртипнең 5.6 һәм 5.7 пунктларында бәян ителгән нигезләмәләрне исәпкә алып;

д) коммерциягә карамаган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтүләр турындагы шартнамәдә һәм Министрлык белән коммерциягә карамаган оешма арасында төзелгән аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант бирү турындагы килешүдә каралган үз бурычлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның шәхси мәгълүматын

коммериягә карамаган оешма территориаль социаль яклау органына бирү өчен әлеге инвалидның ризалыгы;

е) аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның коммерциягә карамаган оешмага хезмәт күрсәтү турында шартнамә төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә эш бирүченең аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны эшкә кабул итүе турында боерык күчермәсен бирү йөкләмәсе;

ж) аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның коммерциягә карамаган оешмага хезмәт күрсәтү турында шартнамә төзелгән көннән дүрт ай эчендә ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр эш бирүчедән хисап чорында фактта эшләнгән вакыт һәм хисап чорында исәпләнгән һәм түләнгән хезмәт хакы күләме турында белешмә (мәгълүмат) турында белешмә кәгазен бирү йөкләмәсе;

з) «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турындагы шартнамә буенча яклар килешүе буенча башка шартлар.

Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү срогы дүрт айдан да артык була алмый. Әлеге срокка Тәртипнең 5.7 пункты нигезендә «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты керми.

4.4. Коммерциягә карамаган оешма хезмәт күрсәтү турында шартнамә төзелгән көннән соң килә торган өч эш көне эчендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид белән хезмәт күрсәтү турында шартнамә төзү хакында язма хәбәр итәргә, анда «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү өчен җаваплы коммерциягә карамаган оешма хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, элемтәгә керү мәгълүматын (эш телефоны номерын, мобиль телефон номерын, электрон почта адресын) күрсәтергә тиеш.

4.5. Хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәнең гамәлдә булуы Россия Федерациясе законнарында, Тәртипнең 5.6 пунктында каралган нигезләрдә вакытыннан алда туктатыла.

4.6. Хезмәт күрсәтү турындагы шартнамә түбәндәге хәлләр килеп чыкканда вакытыннан алда туктатыла:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид вафат булганда;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид Татарстан Республикасы чикләреннән даими яшәү урынына чыкканда;

инвалид «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтеннән баш тартканда;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән Тәртипнең 5.3 пунктындагы «а» пунктчасында каралган чараларны башкару сроклары бозылганда;

эш бирүче тарафыннан аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид белән төзелгән хезмәт шартнамәсе туктатылганда;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидта Тәртипнең 2.2 пунктында китерелгән зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре барлыкка килгәндә.

Хезмәт күрсәтү турында шартнамә түбәндәге очракларда өзелгән дип санала:

әлеге пунктның икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында каралган очракларда – хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәне өзү өчен нигез булган хәлләр барлыкка килгән көндә;

әлеге пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында каралган очракларда – аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид коммерциягә карамаган оешмага хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәне өзү турында хәбәрнамә җибәргән көннән 12 календарь көн узгач;

бу пунктның җиденче абзацында каралган очракта – аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид коммерциягә карамаган оешмага үзендә Тәртипнең 2.2 пунктында китерелгән зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләренең берсе барлыкка килүе турында хәбәр итү көнендә.

4.7. Хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәнең гамәлдә булуы аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның вакытлыча эшкә сәләтсез булуына бәйле рәвештә, шул исәптән аны олыларга стационар ярдәм күрсәтүче медицина оешмасына хастаханәгә салганда әлеге вакыйгалар башланган көннән туктатып торыла һәм аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид эшкә сәләтле булган һәм аны олыларга стационар ярдәм күрсәтүче медицина оешмасыннан чыгарган көннән торгызыла.

4.8. Коммерциягә карамаган оешма хезмәт күрсәтү турында шартнамәне туктатып тору һәм өзүнең барлык очраклары турында территориаль социаль яклау органына хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәне туктатып торган (өзгән) көннән соң килә торган бер эш көне узганга кадәр хәбәр итәргә тиеш.

## V. Коммерциягә карамаган оешмага карата таләпләр

5.1. Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәткәндә коммерциягә карамаган оешма түбәндәгеләргә бурычлы:

хезмәт күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен тиешле сыйфатта күрсәтүне тәэмин итәргә;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны аның үтенече буенча коммерциягә карамаган оешма үз эшчәнлеген алып бара торган документлар белән таныштыруны тәэмин итәргә;

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү кысаларында хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын эчке контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга, шулай ук Министрлыкка һәм Министрлык тарафыннан вәкаләт бирелгән учреждениеләргә аны күрсәтүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итәргә;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүне башкаручы персоналны алыштыру турында мотивлаштырылган таләбе кергән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырырга;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәргә, Россия Федерациясе законнары белән конфиденциаль характердагы мәгълүматка яисә хезмәт урынында файдаланыла торган мәгълүматка кертелгән һөнәри, хезмәт һәм (яисә) башка вазыйфаларны үтәүгә бәйле рәвештә билгеле булган аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидлар турындагы мәгълүматны таратмауны тәэмин итәргә;

төшерелмәгән яки юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган хезмәткәрләргә (персоналга) «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтергә рөхсәт итмәскә;

Тәртипнең 5.3 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән, үткәрелгән чаралар йомгаклары буенча хисап мәгълүматын, шулай ук Тәртипнең 5.3 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында каралган документларны территориаль социаль яклау органына кертергә;

хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәдә билгеләнгән, аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларның «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтеннән файдалануга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле булган башка бурычларны үтәргә.

5.2. Коммерциягә карамаган оешманың «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте кысаларында социаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү өчен кирәк булган, Тәртипнең 6.4 пунктында каралган таләпләргә туры килә торган персоналы булырга тиеш.

5.3. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәткәндә, коммерциягә карамаган оешма түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларны хөрмәт итүне һәм аларга карата гуманлы мөнәсәбәттә булуны, аларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне;

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга карата көч, шул исәптән физик яки психологик көч куллануны, аларны кимсетүне, алар белән тупас мөгамәләдә булуны булдырмауны;

Шартнамәдә билгеләнгән, инвалидларның «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен файдалануга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле булган башка бурычларны үтәүне.

5.4. Коммерциягә карамаган оешманың аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы персоналы:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга эшкә урнашуда яки социаль хезмәтләр күрсәтүдә ярдәм күрсәтү тәҗрибәсе булырга тиеш;

гамәлгә кую документларында каралган таләпләрне үтәргә, учреждениедә кабул ителгән тәртипне үтәргә, үзенә йөкләнгән функциональ вазыйфаларны сыйфатлы итеп башкарырга тиеш.

## VI. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү тәртибе

6.1. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү кысаларында коммерциягә карамаган оешма хезмәткәрләре (персонал) Тәртипнең кушымтасы нигезендә хезмәтләр күрсәтә.

2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибенә һәм шартларына кушымта

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәткәндә хезмәт һәм социаль хезмәтләр кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар исемлеге

| Т/с | Чараның исеме | Хезмәт күрсәтүнең күләме | |
|---|---|---|---|
| | | үлчәү берәмлеге | саны |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларны эш белән тәэмин итүне оештырганда булышлык күрсәтеп торуның индивидуаль планын эшләү | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 2. | «Россиядә эш» порталында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны теркәү | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 3. | Һөнәри диагностика үткәрү: | | |
| 3.1. | тест ясауны оештыру | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 3 тапкыр |
| 3.2. | мөмкин булган эшчәнлек төрләрен сайлау | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 3.3. | предприятиеләргә һәм оешмаларга экскурсияләр уздыру | хезмәт күрсәтү | кимендә ике экскурсия |
| 4. | инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасындагы тәкъдимнамәләр нигезендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидлар өчен яраклы эш вариантларын эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән үзара хезмәттәшлекне оештыру | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында кимендә 4 тапкыр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5. | Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның резюмесын әзерләү һәм эш бирүчеләр белән әңгәмә уздырганда ярдәм күрсәтү | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 6. | Эш бирүчене эзләү: | | |
| 6.1. | аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча эш бирүче белән очрашу | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында кимендә 2 тапкыр |
| 6.2. | эш бирүче вәкилләре белән түгәрәк өстәл утырышы, шул исәптән аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның хезмәт шартлары үзенчә-лекләрен һәм эш көне тәртибен билгеләү | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 7. | Медицина комиссиясен узу өчен документлар җыюда ярдәм итү | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 8. | Хезмәт шартнамәсе төзегәндә булышлык күрсәтеп тору | хезмәт күрсәтү | хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 9. | Эш урынында булышлык күрсәтеп тору (кимендә 14 эш көне) | хезмәт күрсәтү | эшкә урнашу урыны буенча ике ай эчендә 14 тапкыр |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 июнь, 727 нче
карары белән расланды

2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү
тәртибе

I. Субсидия рәвешендә грант бирү турында гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплексны булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карары белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплексны булышлык күрсәтеп тору концепциясен гамәлгә ашыру чараларын үтәү максатларында эшләнде һәм 2023 – 2026 елларда «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) булмаган) (алга таба – коммерциягә карамаган оешма) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант (алга таба – субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирүнең максаты – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче карары белән расланган 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары (алга таба – Пилот проектын тормышка ашыру тәртибе һәм шартлары) нигезендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган, Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән инвалидларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп тору.

1.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчачы белән баш эш итүче – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә

җиткерелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.4. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.5. Субсидия Министрлык тарафыннан коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә тәкъдимнәр (заявкалар) сорау юлы белән үткәрелә торган сайлап алу (алга таба – заявка, сайлап алу) нәтиҗәләре буенча, коммерциягә карамаган оешмаларның сайлап алу критерийларына туры килүдән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып бирелә.

1.6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәтен оештыруга һәм күрсәтүгә турыдан-туры бәйле хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр өчен түләү чыгымнары;

транспорт хезмәтләре, элемтә хезмәтләре өчен чыгымнар;

чит оешмалар белән шартнамәләрдә һәм «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү өчен җәлеп ителгән белгечләр белән гражданлык-хокукый шартнамәләрдә каралган чыгымнар.

1.7. Заявкаларны кабул итү планлаштырылган айның беренче числосыннан да иртәрәк булмаган датага коммерциягә карамаган оешмалар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процессы билгеләнмәү, коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки коммерциягә карамаган оешмаларның баш

бухгалтерлары (булганда) турында мәгълүматлар булмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.

1.8. Коммерциягә карамаган оешма түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга эшкә урнашуда яки социаль хезмәтләр күрсәтүдә ярдәм күрсәтү тәҗрибәсе кимендә бер ел булырга тиеш;

«Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, Пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартларының 6.4 пунктында каралган таләпләргә туры килә торган квалификацияле персоналы булу;

сайлап алу үткәрелә торган айга кадәрге ел дәвамында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларның коммерциягә карамаган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына карата Министрлык тарафыннан нигезле дип танылган биш һәм аннан күбрәк шикаяте булмау;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән.

## II. Сайлап алуны уздыру шартлары һәм тәртибе

2.1. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган

биш көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

гаризалар бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасы, ул сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итәлә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 1.7 һәм 1.8 пунктлары нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләр һәм критерийлар, әлеге таләпләргә һәм критерийларга туры килүен раслау өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 2.2 – 2.5 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 2.9 – 2.12 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыруның сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган датасы.

2.2. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар әлеге Тәртипнең кушымтасында күрсәтелгән форма буенча Министрлык адресына заявка җибәрә, анда «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтергә планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округындагы районнары, шәһәр округлары) исемнәре һәм бу хезмәт күрсәтү планлаштырыла торган кеше саны күрсәтелә, шулай ук коммерциягә карамаган оешма турындагы, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны, сайлап алуга бәйле коммерциягә карамаган оешма турындагы башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирелә.

2.3. Заявкага түбәндәге документлар (документлар күчермәләре) теркәлә:

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым органы тарафыннан бирелгән, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган салым түләүченең (җыемнар түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләве турында белешмә кәгазе;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты алдында акчалата йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган, коммерциягә карамаган оешманыңмөһер белән расланган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешмаларның үзгәртеп оештыру процессында булмавын (башка юридик затны коммерциягә карамаган оешмага кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерелмәвен, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) кул куйган һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазе;

коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затка яки коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтерына (баш бухгалтеры булганда) Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү тәртибен, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе формаларын раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) соратыла торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турында, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган документларның күчермәләре;

коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган эш бирүченең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавы турында белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешманың аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларга эшкә урнашуда яки социаль хезмәтләр күрсәтүдә ярдәм күрсәтү тәҗрибәсе кимендә бер ел булуы, «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, Пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартларының 6.4 пунктында каралган таләпләргә туры килә торган квалификацияле персоналы булуын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазе;

сайлап алу үткәрелә торган айга кадәрге ел дәвамында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидларның коммерциягә карамаган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына карата Министрлык тарафыннан нигезле дип танылган биш һәм аннан күбрәк шикаяте булмау турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазе;

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан әлеге пунктның икенче, бишенче, җиденче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.4. Заявка, шулай ук аңа теркәлгән документлар һәм белешмәләр бер яки берничә папкага (томнарга) брошюра итеп тегелгән, һәр бите номерланган һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган булырга тиеш. Берничә папка (томнар) булганда, папка (томнар) номеры һәм һәр папкада (томда) битләр саны күрсәтелә.

Заявка конвертка салып беркетелә: анда «2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү хокукына сайлап алуда катнашуга заявка».

2.5. Заявка һәм аңа теркәлә торган барлык документлар почта элемтәсе аша җибәрелергә яисә турыдан-туры Министрлыкка тапшырылырга мөмкин.

Коммерциягә карамаган оешмалар бер генә заявка бирә ала, заявкага үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

2.6. Заявка коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан Министрлыкка тиешле язма мөрәҗәгать җибәрү юлы белән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганга кадәр кире алынырга мөмкин. Министрлык мөрәҗәгать кергән көннән 10 эш көне эчендә коммерциягә карамаган оешмаларга бирелгән заявканы һәм аңа теркәлә торган документларны почта элемтәсе аша җибәрергә тиеш.

2.7. Министрлык коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тапшырылган заявкаларны һәм аларга теркәлә торган документларны, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кабул итә һәм заявкаларны теркәү журналында аларга тәртип буенча теркәү номеры биреп терки. Заявка почта аша кергәндә, ул кергән көнендә заявкаларны теркәү журналында теркәлә, анда Министрлыкка почта аша керү датасы һәм вакыты күрсәтелә.

Заявка кулдан бирелгән очракта, Министрлык, аны алу датасын һәм тәртип буенча теркәү номерын биреп, коммерциягә карамаган оешмага заявка алу турында расписка бирә.

Теркәлгән заявкалар кушымта итеп бирелгән документлар белән коммерциягә карамаган оешмаларга кире кайтарылмый һәм Министрлыкта саклана.

2.8. Заявканы сайлап алу яисә бирү тәртибе буенча аңлатмалар алу кирәк булган очракта, коммерциягә карамаган оешмалар Министрлыкка язмача яки шәхсән мөрәҗәгать итә ала. Коммерциягә карамаган оешмалардан өстәмә аңлатмалар бирү кирәклеге турында язма сорау алганда ул кергән көннән алып өч эш көне эчендә Министрлык аңлатмаларны язма рәвештә почта элемтәсе аша җибәрергә тиеш, телдән мөрәҗәгать иткәндә аңлатмалар турыдан-туры мөрәҗәгать иткән коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле вәкиленә мөрәҗәгать иткән көнне телдән бирелә. Аңлатмалар сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән бирелә һәм заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә кадәр биш календарь көн алдан туктатыла.

2.9. Субсидия бирү өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алуны уздыру максатларында Министрлык заявкаларны карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) төзи.

Комиссиянең составы һәм Комиссиянең эш тәртибен билгели торган нигезләмәсе Министрлыкның хокукый акты белән раслана.

Комиссия составына шул исәптән Министрлык каршындагы иҗтимагый совет әгъзалары да керә.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән килә торган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

керү чиратына карап, заявкаларны (шул исәптән почта элемтәсе аша кергәннәрне) карап тикшерүне гамәлгә ашыра һәм коммерциягә карамаган оешмаларның әлеге Тәртипнең 1.7 һәм 1.8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүен һәм әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тикшерә;

заявканың һәм коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүе турында яисә әлеге Тәртипнең 2.10 пунктында каралган нигезләр буенча заявканы кире кагу турында карар кабул

итә;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәрен билгели.

Әгәр утырышта комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Сайлап алуда җиңүчегә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидия күләме Комиссия тарафыннан заявканы теркәгәндә бирелгән тәртип номеры һәм әлеге Тәртипнең 2.11 һәм 3.2 пунктлары нигезендә билгеләнә.

Комиссия әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән срокта Комиссия утырышының беркетмәсен төзи, анда заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны, заявкаларның тәртип саннары, заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат, заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп) мәгълүмат; сайлап алуда җиңгәнкоммерциягә карамаган оешмалар исемнәре (аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәрен күрсәтеп) күрсәтелә.

Заявка алынмаган очракта, Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән 10 эш көне эчендә әлеге карар турында коммерциягә карамаган оешмага язмача хәбәр итә.

Сайлап алуда җиңүчегә (җиңүчеләргә) субсидия бирү турында карар Министрлык тарафыннан сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләр) билгеләгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә кабул итә.

2.10. Карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 1.7 һәм 1.8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган заявканың һәм әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән документларның сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргәә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан заявкалар һәм документлар заявкаларны бирү өчен билгеләнгән датага һәм (яисә) вакытка кадәр бирелүе.

2.11. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве яки әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында каралган документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән

очракта, Комиссия әлеге карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә субсидия алучыга, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында язма рәвештә хәбәр итә.

2.12. Субсидия күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = N \times C,$$

монда:

N – «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтергә планлаштырыла торган кеше саны;

С – «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган тариф.

2.13. Министрлык заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән алып 15 эш көне тәмамланганчыга кадәр бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра, анда түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

2.14. «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте өчен тариф социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә исәпләп чыгарылган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативлары нигезендә исәпләнә.

## III. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Министрлык субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша субсидия алучыларның заявкасында күрсәтелгән электрон почта адресына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидия бирү турында килешүнең бертип формасы нигезендә субсидия бирү хакында килешү проектын җибәрә.

Субсидия алучыдан субсидия алу турында имзаланган килешүне алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык субсидия бирү турындагы килешүгә имза куя һәм аның бер нөсхәсен субсидия алучыга җибәрә.

Әгәр субсидия алучының электрон почта адресына субсидия бирү турында килешү проекты килгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия алучы тарафыннан үзе имзаланган субсидия бирү турындагы килешү Министрлыкка тапшырылмаган булса, әлеге субсидия алучыга субсидия бирү турында карар

гамәлдән чыгарылган, ә субсидия алучы субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип санала. Министрлык субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка үзе ягыннан имза куелган субсидия бирү турында килешүне тапшыру срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия алучыга субсидия бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында язмача хәбәр итә.

Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәге нигезләмәләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидияне күчерү тәртибе, субсидия бирүне тәмамлауның төгәл датасы һәм аны бирү нәтиҗәсенең ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең конкрет микъдар характеристикасы), субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү буенча субсидия алучының бурычы, аңа ирешмәгән өчен җаваплылык, хисаплылык, өстәмә хисап (кирәк булганда) бирү сроклары һәм формалары;

элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, субсидия алучы белән субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешеп булмаганда субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакында, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт;

субсидия алучы тарафыннан субсидияне кире кайтару тәртибе, сроклары, субсидия бирү турында төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр, субсидия бирү турында килешү шартларын бозган өчен җаваплылык;

субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган, субсидия күчерелә торган исәп-хисап яки корреспондент счеты реквизитлары;

субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

субсидия алучы, шулай ук субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

Субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү, шулай ук субсидия бирү турындагы килешүне өзү яклар килешүе буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидия бирү турындагы килешүнең бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.2. Субсидияләр алучыларга субсидияләрне күчерү Министрлык раслаган форма буенча 2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү турындагы заявканы Министрлыкка тапшырганда субсидияләр алучыларның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

субсидиянең 25 проценты – субсидия алучы тарафыннан аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид белән төзелгән «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү турында шартнамә күчермәсе тапшырылган көннән алып 5 эш көне эчендә;

субсидиянең 50 проценты – субсидия алучы тарафыннан эш бирүченең аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидны эшкә кабул итү турындагы боерыгының субсидия алучы җитәкчесе тарафыннан имза куелган һәм субсидия алучының мөһере сугылган күчермәсе тапшырылган көннән алып 5 эш көне эчендә;

субсидиянең 25 проценты – эш бирүче тарафыннан аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидка эшкә урнашкан көннән ике ай эчендә аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидның хезмәт эшчәнлеген башкаруы һәм тиешле эш чорына аңа исәпләнгән һәм түләнгән хезмәт хакының күләме турында бирелгән белешмәләрнең расланган күчермәләре һәм субсидия алучы белән эшкә урнашкан көннән ике ай эчендә «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтелгән аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалид кул куйган хезмәт күрсәтүләрнең тапшыру-кабул итү актларының күчермәләре субсидия алучы тарафыннан тапшырылган көннән 5 эш көне эчендә.

## IV. Субсидия бирү нәтиҗәсе һәм хисапка карата таләпләр

4.1. Субсидия бирү нәтиҗәсе – агымдагы календарь елның 15 декабренә кадәр «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтелгән, эшкә урнашу урыны буенча кимендә ике ай эшләгән аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидлар саны.

4.2. Субсидия алучылар Министрлыкка ай саен, субсидия бирүнең хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, түбәндәгеләр тапшырыла:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән, субсидия бирү турындагы килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән, килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны башкару турында хисап.

Министрлык субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

4.3. Әлеге Тәртипнең 2.2, 2.3 һәм 4.2 пунктларында күрсәтелгән, субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган белешмәнең, документларның һәм хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыга йөкләнә.

V. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

5.1. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

5.2. Субсидия аны алучы тарафыннан Министрлыкның яки дәүләт финанс контроле органнарының тиешле таләбен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар бирелгәндә, субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда – тулы күләмдә;

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) тапшырылмаганда, шулай ук күрсәтелгән хисапларны тапшыру сроклары бозылганда – тулы күләмдә;

әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгәндә – субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченнән тайпылуга пропорциональ билгеләнә торган күләмдә;

субсидия акчасын максатчан файдаланмау ачыкланганда – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә.

Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше субсидияләр алучылар тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында билгеләнгән субсидияне ирекле кире кайтару срогы бозылган очракта, Министрлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

Шул ук вакытта субсидия алучылар субсидияне ирекле кире кайтару срогы чыккан көннән соң килә торган көннән алып аны кире кайтару көненә (кире кайтару көнен кертеп) кадәр кичектерелгән һәр көн өчен кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасының 0,03 проценты күләмендә пеня түлиләр.

2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенә кушымта

Форма

2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торугә бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү хокукына сайлап алуда катнашуга заявка

| | |
|---|---|
| Оештыру һәм хокук формасын күрсәтеп, коммерциягә карамаган оешма исеме | |
| Коммерциягә карамаган оешманың теркәлү урыны | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Исәпкә кую сәбәбенең коды (КПП) | |
| Төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) | |
| Коммерциягә карамаган оешманы дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| Коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда), элемтәгә керү телефоны, e-mail | |
| Веб-сайт, социаль челтәрләр | |
| Муниципаль районнар (шәһәр округлары) яктылыгында «Эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтеләчәк аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган инвалидлар саны | |

| | |
|---|---|
| Коммерциягә карамаган оешманың банктагы түләү реквизитлары, e-mail, телефоны, факсы | |

Әлеге заявкадагы һәм аңа теркәлә торган документлардагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм һәм коммерциягә карамаган оешма турындагы мәгълүматны, сайлап алуда катнашу өчен бирелә торган заявканы, тиешле сайлап алуга бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирәм.

Дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм:

электрон документ рәвешендә почта адресы буенча язма рәвештә ________________________________________________;

электрон почта адресы буенча ________________________.

Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

| Т/с | Документ исеме | Саны | |
|---|---|---|---|
| | | нөсхә | бит |
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Җитәкче ___________ _________________________ ______________
(имза) (имзаны таркатып язу) (дата)

М.У.

Баш бухгалтер ___________ _________________________ ______________
(булганда) (имза) (имзаны таркатып язу) (дата)

_____________________________